ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, , 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы, 37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 2** **15 февраль 2016 ел**

**Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 431 маддәсе, 2009 елның 9 февралендәге «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында»гы 14-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2015 елның 3 ноябрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 92-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешү нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү буенча эш барышында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгының 2016 елның 12 февралендәге 13 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге регламентына таянып эш итәргә;

регистрга кертелергә тиешле муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне район башкарма комитетына җибәрү өчен җаваплы затларны билгеләргә;

регистрны оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка чаралар күрергә.

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендта һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә игълан итәргә www.yutaza.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге
башлыгы: З.М.Әһлиева